Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Елховой авылы башкарма комитеты

КАРАР №4

«15» июль 2020 ел

Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен
анализлау тәртибен раслау турында

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2020 елның 16 декаберендәге 1251 п номерлы күрсәтмәсен карап,

КАРАР БИРӘМ:

1. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Елховой авылы, Совет урамы, 67 йорт; «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үземдә калдырам.

Елховой авылы башкарма
комитеты җитәкчесе Д.Р.Хәйрисламова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЕЛХОВОЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЕЛХОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Р.06-1389/12
ЕЛХОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1644036400
КПП 164401001
ОГРН 1061644003552

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Елховой авылы башкарма
комитетының 2020 елның
«15» июлендәге 4 нче
карарына 1 нче кушымта

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы N 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авылы башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Елховой авылы башкарма комитеты кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тиешле чорда килгән, шул исәптән: Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында теркәлгән "Электрон Хөкүмәт" телефоны буенча язма рәвештә, Интернет-кабул итү бүлмәсенә яисә электрон почта аша, гражданнарны шәхсән кабул итү барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше системасында теркәлгән "кайнар линия" телефоны буенча кергән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында җирле үзидарә органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясый.

3. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау елга 1 тапкыр башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә анализда кергән, яңадан каралган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат булырга тиеш.

5. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ җирле үзидарә органнары тарафыннан Әлмәт муниципаль районының Елховой авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.

6. Әлеге тәртипне бозуда гаепле вазыйфаи затлар кануннарда каралган җаваплылыкка тартылалар.

Елховой авылы башкарма
комитеты җитәкчесе Д.Р.Хәйрисламова